**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об оценке регулирующего воздействия проектов нормативных правовых актов Республики Татарстан, установлении и оценке применения обязательных требований, содержащихся в нормативных правовых актах Республики Татарстан, и экспертизе нормативных правовых актов Республики Татарстан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 марта 2023 года

## Статья 1

Внести в Закон Республики Татарстан от 7 марта 2014 года № 14-ЗРТ «Об оценке регулирующего воздействия проектов нормативных правовых актов Республики Татарстан, установлении и оценке применения обязательных требований, содержащихся в нормативных правовых актах Республики Татарстан, и экспертизе нормативных правовых актов Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2014, № 3; 2016, № 3; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2019, № 60 (часть I); 2021, № 77 (часть I); 2022, № 90 (часть I) следующие изменения:

1) в статье 1:

а) в пункте 1:

в абзаце первом слова «Президента Республики Татарстан» заменить словами «Главы (Раиса) Республики Татарстан»;

в подпункте «а» слова «устанавливающих новые, изменяющих или отменяющих» заменить словами «устанавливающих новые или изменяющих»;

в подпункте «б» слова «устанавливающих новые, изменяющих или отменяющих» заменить словами «устанавливающих новые или изменяющих»;

в подпункте «в» слова «устанавливающих, изменяющих или отменяющих» заменить словами «устанавливающих или изменяющих»;

б) в пункте 2 слова «Президента Республики Татарстан» заменить словами «Главы (Раиса) Республики Татарстан»;

2) подпункт «б» пункта 3 части 1 статьи 2 изложить в следующей редакции:

«б) подлежащих принятию при угрозе возникновения и (или) возникновении отдельных чрезвычайных ситуаций, введении режима повышенной готовности, чрезвычайной ситуации или разрабатываемых в целях реализации мер, принимаемых в рамках особых режимов, вводимых в целях реализации положений Федерального конституционного закона от 30 января 2002 года № 1-ФКЗ «О военном положении».»;

3) в пункте 1 части 1 статьи 3 после слов «Республики Татарстан» дополнить словами «, осуществляющим государственное управление в соответствующей сфере», слова «осуществляющим подготовку соответствующего проекта» заменить словами «подготавливающим соответствующий проект»;

4) статью $3^1$ изложить в следующей редакции:

«Статья $3^1$. **Порядок установления и оценки применения обязательных требований, содержащихся в нормативных правовых актах, в том числе оценки фактического воздействия нормативных правовых актов**

1. Установление и оценка применения обязательных требований, содержащихся в нормативных правовых актах, в том числе оценка фактического воздействия нормативных правовых актов, осуществляются в соответствии с принципами установления и оценки применения обязательных требований, определенными федеральным законом, и с настоящим Законом.

2. Положения нормативных правовых актов, устанавливающих обязательные требования, должны вступать в силу либо с 1 марта, либо с 1 сентября соответствующего года, но не ранее чем по истечении 90 дней после дня официального опубликования соответствующего нормативного правового акта, если иное не установлено федеральным законодательством.

3. Положения части 2 настоящей статьи не применяются в отношении нормативных правовых актов, подлежащих принятию в целях предупреждения террористических актов и ликвидации их последствий, предупреждения угрозы обороне страны и безопасности государства, при угрозе возникновения и (или) возникновении отдельных чрезвычайных ситуаций, введении режима повышенной готовности или чрезвычайной ситуации, а также нормативных правовых актов, направленных на недопущение возникновения последствий обстоятельств, произошедших вследствие непреодолимой силы, то есть чрезвычайных и непредотвратимых при данных условиях обстоятельств, в частности эпидемий, эпизоотий, техногенных аварий и катастроф.

4. Положения нормативных правовых актов, которыми вносятся изменения в ранее принятые нормативные правовые акты, могут вступать в силу в иные, чем указано в части 2 настоящей статьи, сроки, если в заключении об оценке регулирующего воздействия установлено, что указанные изменения вносятся в целях

снижения затрат физических и юридических лиц в сфере предпринимательской и иной экономической деятельности на исполнение ранее установленных обязательных требований и не предусматривают установление новых условий, ограничений, запретов, обязанностей.

5. Постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан, нормативным правовым актом подведомственного ему органа исполнительной власти Республики Татарстан, содержащим обязательные требования, должен предусматриваться срок его действия, который не может превышать шесть лет со дня его вступления в силу, за исключением случаев, установленных законом Республики Татарстан или принятым в соответствии с ним нормативным правовым актом Кабинета Министров Республики Татарстан.

6. По результатам оценки применения обязательных требований в порядке, определяемом Кабинетом Министров Республики Татарстан, может быть принято решение о продлении установленного нормативным правовым актом, содержащим обязательные требования, срока его действия не более чем на шесть лет.

7. Положения частей 5 и 6 настоящей статьи не применяются в отношении постановлений Кабинета Министров Республики Татарстан, нормативных правовых актов подведомственных ему органов исполнительной власти Республики Татарстан, направленных на реализацию проектов государственно-частного партнерства, в том числе достижение целей и задач таких проектов, которые осуществляются на основе соглашений о государственно-частном партнерстве, предусмотренных Федеральным законом от 13 июля 2015 года № 224-ФЗ «О государственно-частном партнерстве, муниципально-частном партнерстве в Российской Федерации и внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации», публичным партнером по которым выступает Республика Татарстан.

8. При установлении обязательных требований постановлениями Кабинета Министров Республики Татарстан, нормативными правовыми актами подведомственных ему органов исполнительной власти Республики Татарстан должны быть определены:

1) содержание обязательных требований (условия, ограничения, запреты, обязанности);

2) лица, обязанные соблюдать обязательные требования;

3) в зависимости от объекта установления обязательных требований:

а) осуществляемая деятельность, совершаемые действия, в отношении которых устанавливаются обязательные требования;

б) лица и используемые объекты, к которым предъявляются обязательные требования при осуществлении деятельности, совершении действий;

в) результаты осуществления деятельности, совершения действий, в отношении которых устанавливаются обязательные требования;

4) формы оценки соблюдения обязательных требований (государственный контроль (надзор), привлечение к административной ответственности, предоставление лицензий и иных разрешений, аккредитация, оценка соответствия продукции и иные формы оценки и экспертизы);

5) органы исполнительной власти Республики Татарстан, осуществляющие оценку соблюдения обязательных требований.

9. Порядок оценки применения обязательных требований, содержащихся в нормативных правовых актах, в том числе оценки фактического воздействия нормативных правовых актов, определяется Кабинетом Министров Республики Татарстан.

10. Регулирующий орган в порядке, определяемом Кабинетом Министров Республики Татарстан, готовит доклад о достижении целей введения обязательных требований. Указанным порядком определяется также порядок рассмотрения доклада о достижении целей введения обязательных требований и принятия решения о продлении срока действия нормативного правового акта, содержащего обязательные требования, или о проведении оценки фактического воздействия нормативного правового акта, содержащего обязательные требования.»;

5) в части 5 статьи 4:

а) в абзаце первом слова «Президента Республики Татарстан» заменить словами «Главы (Раиса) Республики Татарстан»;

б) в пункте 1 слова «Президент Республики Татарстан» в соответствующем падеже заменить словами «Глава (Раис) Республики Татарстан» в соответствующем падеже.

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования.

Глава (Раис)
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РАИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
06 апреля 2023 года
№ 27-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 23 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» 2014 елның 7 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 3; 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 60 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 90 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

а) 1 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

«а» пунктчасында «яңаларын билгеләүче, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында элек каралганнарын үзгәртүче яисә юкка чыгаручы» сүзләрен «яңаларын билгеләүче яисә Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында элек каралганнарын үзгәртүче» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктчасында «яңаларын билгеләүче, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында элек каралганнарын үзгәртүче яисә юкка чыгаручы» сүзләрен «яңаларын билгеләүче яисә Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында элек каралганнарын үзгәртүче» сүзләренә алмаштырырга;

«в» пунктчасында «билгеләүче, элек билгеләнгәнен үзгәртүче яисә юкка чыгаручы» сүзләрен «билгеләүче яисә элек билгеләнгәнен үзгәртүче» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктының «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) аерым гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы булганда һәм (яисә) алар килеп чыкканда, югары әзерлек, гадәттән тыш хәл режимы кертелгәндә кабул ителергә тиешле булган яисә «Сугыш хәле турында» 2002 елның 30 гыйнварындагы 1-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максатларында кертелә торган аерым режимнар кысаларында күрелә торган чараларны гамәлгә ашыру максатларында эшләнә торган.»;

3) 3 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында «әзерли торган» сүзләреннән соң «тиешле тармакта дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы» сүзләрен өстәргә;

4) $3^1$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$3^1$ статья. **Норматив хокукый актларда булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү, шул исәптән норматив хокукый актларның факттагы йогынтысын бәяләү тәртибе**

1. Норматив хокукый актларда булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү, шул исәптән норматив хокукый актларның факттагы йогынтысын бәяләү мәҗбүри таләпләрне билгеләүнең һәм аларны куллануның федераль законда билгеләнгән принциплары һәм әлеге Закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Мәҗбүри таләпләрне билгеләүче норматив хокукый актлар нигезләмәләре тиешле елның йә 1 мартыннан, йә 1 сентябреннән, әмма, федераль законнарда башкасы билгеләнмәгән булса, тиешле норматив хокукый акт рәсми басылып чыккан көннән соң 90 көннән дә иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керергә тиеш.

3. Әлеге статьяның 2 өлеше нигезләмәләре террорчылык актларын кисәтү һәм аларның зыяннарын бетерү, илнең оборонасына һәм дәүләтнең иминлегенә янаган куркынычны кисәтү максатларында, аерым гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы булганда һәм (яисә) алар килеп чыкканда, югары әзерлек режимы яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгәндә кабул ителергә тиешле норматив хокукый актларга, шулай ук җиңеп чыга алмаслык көч аркасында килеп чыккан хәлләрнең, ягъни гадәттән тыш һәм бу шартларда каршы тора алмаслык хәлләрнең, аерым алганда эпидемияләрнең, эпизоотияләрнең, техноген аварияләрнең һәм һәлакәтләрнең, зыяннарын булдырмауга юнәлдерелгән норматив хокукый актларга карата кулланылмый.

4. Элек кабул ителгән норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертә торган норматив хокукый актлар нигезләмәләре, җайга салу йогынтысын бәяләү турындагы бәяләмәдә бу үзгәрешләрнең физик һәм юридик затларның эшкуарлык эшчәнлеге һәм башка икътисадый эшчәнлек өлкәсендә элек билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне башкару чыгымнарын киметү максатларында кертелә һәм яңа шартларны, чикләүләрне, тыюларны, бурычларны күздә тотмый дип билгеләнсә, әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән сроклардан башка срокларда үз көченә керергә мөмкин.

5. Мәҗбүри таләпләр булган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарында, аңа ведомство буйсынуындагы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органы норматив хокукый актында аларның гамәлдә булу срогы каралырга тиеш, ул, Татарстан Республикасы законнарында яисә аның нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый актында билгеләнгән очраклардан тыш, үз көченә кергән көннән алып алты елдан да артык була алмый.

6. Мәҗбүри таләпләрне кулллануны бәяләү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә аларның мәҗбүри таләпләр булган норматив хокукый актта билгеләнгән гамәлдә булу срогын иң күбе алты елга озайту турында карар кабул ителергә мөмкин.

7. Әлеге статьяның 5 һәм 6 өлешләре нигезләмәләре Татарстан Республикасы гавами партнер булган дәүләти-хосусый партнерлык проектларын гамәлгә ашыруга, шул исәптән «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законда каралган дәүләти-хосусый партнерлык турында килешүләр нигезендә гамәлгә ашырыла торган проектларның максатларына һәм бурычларына ирешүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына, аңа ведомство буйсынуындагы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларына карата кулланылмый.

8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм аңа ведомство буйсынуындагы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актлары белән мәҗбүри таләпләр билгеләнгәндә түбәндәгеләр билгеләнергә тиеш:

1) мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеге (шартлар, чикләүләр, тыюлар, бурычлар);

2) мәҗбүри таләпләрне үтәргә тиешле затлар;

3) мәҗбүри таләпләрне билгеләү объектына бәйле рәвештә:

а) мәҗбүри таләпләр билгеләнә торган эшчәнлек, башкарыла торган гамәлләр;

б) эшчәнлекне гамәлгә ашырганда, гамәлләрне башкарганда мәҗбүри таләпләр куела торган затлар һәм файдаланыла торган объектлар;

в) үзләренә карата мәҗбүри таләпләр билгеләнә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыруның, гамәлләр башкаруның нәтиҗәләре;

4) мәҗбүри таләпләрне үтәүне бәяләүнең рәвешләре (дәүләт контроле (күзәтчелеге), административ җаваплылыкка тарту, лицензияләр һәм башка рөхсәтләр бирү, аккредитацияләү, продукциянең туры килүен бәяләү һәм бәяләүнең һәм экспертизаның башка рәвешләре);

5) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәҗбүри таләпләрне үтәүне бәяләүче органнары.

9. Норматив хокукый актлардагы мәҗбүри таләпләрне куллануны бәяләү, шул исәптән норматив хокукый актларның факттагы йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан үткәрелә.

10. Җайга салучы орган мәҗбүри таләпләрне кертү максатларына ирешү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә доклад әзерли. Әлеге тәртип белән шулай ук мәҗбүри таләпләрне кертү максатларына ирешү хакындагы докладны карау һәм мәҗбүри таләпләр булган норматив хокукый актның гамәлдә булу срогын озайту турында яисә мәҗбүри таләпләр булган норматив хокукый актның факттагы йогынтысын бәяләүне уздыру хакында карар кабул итү тәртибе билгеләнә.»;

5) 4 статьяның 5 өлешендә:

а) беренче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 пунктта тиешле килештәге «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен тиешле килештәге «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ / АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2023 ел, 06 апрель
№ 27-ТРЗ